МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.09.2014 Казан ш. № 5371/14

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында мәгълүматлар төбәк банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт мәгълүмат банкы хакында» 2001 елның 16 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, боерам:

1. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында белешмәләрнең төбәк банкын формалаштыру, алып бару һәм алардан файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.
2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында белешмәләр дәүләт банкының төбәк операторы вәкаләтләрен үтәү буенча опека һәм попечительлек буенча эшчәнлек оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт идарәсе функциясен гамәлгә ашыру кысаларында административ регламентын раслау турында» 2009 елның 21 октябрендәге 2027/09 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2009 елның 21 октябрендәге 2027/09 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында белешмәләр дәүләт банкының төбәк операторы вәкаләтләрен үтәү буенча административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 10 февралендәге 476/10 номерлы боерыгы;

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары С.В. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Министр Э.Н. Фәттахов

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 22.09.2014 №5371/14 боерыгы белән расланган**

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында региональ белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм алардан файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм алардан файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба - дәүләт хезмәте) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча стандартны, гамәлләрнең (административ процедураларның) тәртибен һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бирүчеләр түбәндәгеләр була:

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга, аларны опекага (попечительлеккә) яисә тәрбиягә алган гаиләләргә алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары;

Россия Федерациясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нигезләр булганда, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар..

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы - ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт мәгълүматларының дәүләт банкының төбәк операторы (алга таба - Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Республика уллыкка алу, опека һәм попечительлек үзәге (алга таба - Үзәк) Министрлыкка дәүләт хезмәте күрсәтү буенча ярдәм күрсәтә.

Россия Федерациясе гражданнары Министрлыкка турыдан-туры (шәхсән) мөрәҗәгать итә.

Россия Федерациясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары яисә гражданлыгы булмаган затлар, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башка тәртип билгеләнмәгән булса, шәхсән яисә чит ил оешмалары вәкиллекләре аша Министрлыкка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 3 йорт, 205, 207 кабинетлар.

Үзәкнең урнашкан урыны: Казан шәһәре, Социалистик урамы, 5 йорт.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, дүшәмбе-пәнҗешәмбе көнне 9.00 дән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.30 дан 13.30 га кадәр.

Үзәкнең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, 8.30 дан 17.00 сәгатькә кадәр, көндезге ашка 12.30 дан 13.00 сәгатькә кадәр.

Бинага үтү шәхесне таныклый торган пропуск һәм (яисә) документ буенча.

Министрлыкның телефоны: 8(843)294-95-66

Үзәкнең телефоннары2й: 533-00-84, 533-00-83; 533-00-82; 533-00-79; факс: 533-00- 81, 533-00-84. Казан коды: 843.

1.3.2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты адресы (алга таба - «Интернет» челтәре):http://www.mon.tatar.ru.

1.3.3. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү урыннарында министрлык биналарында урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.mon.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми сайтында (www.prav.tatar.ru)

Россия Мәгариф министрлыгы ярдәмендә булдырылган интернет-сайтта: www.usynovite.ru (алга таба - Интернет-сайт);

Үзәкнең электрон почтасы (e-mail): children_kazan@mail.ru

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язма рәвештә мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Министрлыкның мәгълүмати технологияләрен һәм куркынычсызлыгын үстерү бүлеге белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла (http://www.mon.tatar.ru).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

Россия Федерациясе Конституциясе (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 26.01.2009, №4, 445 ст.);

Россия Федерациясенең 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы Гаилә кодексы (алга таба - РФ ГК) (РФ законнары җыентыгы, 01.01.1996, № 1, 16 ст.);

Россия Федерациясе Граждан-процессуаль кодексы (РФ законнары җыентыгы 18.11.2002, № 46, 4532 ст.);

«Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкы хакында» 2001 елның 16 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 44-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы 23.04.2001, № 17, 1643 ст.);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыентыгы 31.07.2006, № 31 (I өлеш), 3451 ст.);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 29 мартындагы 275 номерлы «Балаларны уллыкка (кызлыкка) бирү һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә уллыкка алучылар гаиләләрендә яшәү һәм тәрбияләнү шартларын тикшереп тору кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясе гражданнары булган һәм чит ил гражданнары яисә гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан уллыкка алынган балаларны Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан исәпкә кую кагыйдәләрен раслау турында» карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы 10.04.2000, № 15, 1590);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2002 елның 4 апрелендәге 217 номерлы «Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында белешмәләрнең дәүләт банкы турында һәм аны формалаштыруны һәм куллануны тикшереп торуны гамәлгә ашыру турында» карары (алга таба - 217 номерлы Карар) (РФ кануннар җыентыгы 15.04.2002, № 15, 1434 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе территориясендә балаларны уллыкка (кызлыкка) алу һәм аны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча чит дәүләтләр органнарының һәм оешмаларының эшчәнлеге турында» 2006 елның 4 ноябрендәге 654 номерлы карары (Россия Федерациясе законнарының 13.11.2006, № 46, 4801 ст.);

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 21 февралендәге 136 номерлы боерыгы белән расланган Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм

калган балалар турында белешмәләр дәүләт банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану тәртибе (алга таба – Россия Мәгариф министрлыгының 136 номерлы боерыгына Тәртип) (Россия газетасы, № 160, 18.07.2014);

Татарстан Республикасы Гаилә кодексы 2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы 2009, № 1, 4 ст.);

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 3, 212 ст.);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010 № 46, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2144).

**2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты**

| Стандарт таләбе атамасы | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм алардан файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтү | 44-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>136 нчы номерлы Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгына тәртип |
| 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 44-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>136 нчы номерлы Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгына тәртип |
| 2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | төбәк банкка балалар турында белешмәләр кертү өчен нигезләр булмаганда мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту; баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче балалар турында төбәк банкка мөрәҗәгать иткән белешмәләр кертү;<br>төбәк белешмәләр банкында балалар турында белешмәләр булган балаларның анкеталарын танышу өчен мөрәҗәгать итүчегә анкета бирү; балага баруга юллама бирү | 44-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>136 нчы номерлы Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгына тәртип |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы | Төбәк банкка балалар турында мөрәҗәгать иткән гражданнар турында белешмәләр кертү һәм мөрәҗәгать итүчегә төбәк банктан балалар турында ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында мәгълүмат бирү документлар тапшыру датасыннан 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче мөрәҗәгать итүчеләргә алар сайлаган ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балага юллама бирү мөрәҗәгать итүченең баланы карарга ризалыгы чыкканнан соң 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. | 44-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>136 нчы номерлы Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгына тәртип |
| 2.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури булган хезмәтләрнең һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге | 1. Россия Федерациясе гражданы белгечкә аның шәхесен раслый торган документ күрсәтә һәм түбәндәгеләрне тапшыра:<br>а) Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 136 номерлы боерыгына 12 нче кушымтада китерелгән форма буенча баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алу теләге турында һәм аны, балалар турында дәүләт банкында исәптә булган, теләкләренә туры килә торган белешмәләр белән таныштыруны сорап язылган гариза;<br>б) гражданның 1 анкетасының 11 нче кушымтада Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы Боерыгына китерелгән форма буенча тутырылган өлеше;<br>в) Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 136 нчы боерыгына Тәртипнең 13 нче кушымтасында Боерыкка китерелгән форма буенча гражданның яшәү урынында бирелгән гражданның уллыкка алучы, опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында опека һәм попечительлек органы бәяләмәсе; | 44-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 136 номерлы боерыгы 33-34, 40-44 пунктларына тәртип |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2. Россия Федерациясе гражданы баланы уллыкка алу вакытына башка дәүләткә бер елдан артык (эшкә яки башка сәбәпләр аркасында) чыкканда, 1 пунктта күрсәтелгән документлардан тыш, түбәндәге документларны тапшыра:<br>а) уллыкка (кызлыкка) алынган баланы уллыкка (кызлыкка) алу вакытына Россия Федерациясе консуллык учреждениесендә консуллык учетына кую һәм уллыкка (кызлыкка) алу рәсмиләштерү мизгелендә яши торган дәүләткә килгәч аның тормыш шартларын һәм тәрбияләү шартларын тикшереп торуны һәм аны Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 136 номерлы боерыгына тәртибенә 14 һәм 15 нче кушымталарда китерелгән формалар буенча дәүләтнең компетентлы органы биргән консуллык учетына куюны йөкләү;<br>б) компетентлы орган вәкаләтләрен раслый торган чит ил оешмасының лицензиясе (яисә чит ил дәүләте законнарында билгеләнгән башка документ) күчермәсен әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән документларны әзерләү буенча.<br>Документлар, әгәр Россия Федерациясе законнарында яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелергә һәм тәрҗемә Россия Федерациясенең консул учреждениесендә яисә дипломатик вәкиллегендә Россия гражданының яшәү урыны йә Россия Федерациясе территориясендә нотариус тарафыннан таныкланырга тиеш. Документлар аларны биргән көннән алып бер ел дәвамында карауга кабул ителә. Әгәр чит дәүләт законнарында документлар гамәлдә булуының башка срогы каралган булса, алар тиешле дәүләт законнарында билгеләнгән срок дәвамында каралырга мөмкин. | | |

| | | |
|---|---|---|
| | 3. Россия Федерациясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданы, чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат түбәндәгеләрне тапшыра:<br>а)  Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 136 номерлы боерыгына 12 нче кушымтада китерелгән форма буенча баланы уллыкка (кызлыкка) алырга теләге турында гариза һәм аны, балалар турында дәүләт банкындагы белешмәләр белән таныштыруны сорап язылган гариза;<br>б) Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 136 номерлы боерыгына 11 нче кушымтада китерелгән форма буенча гражданның 1 анкетасының тутырылган өлеше;<br>в)  Россия Федерациясе тиешле консуллык учреждениесендә, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 136 нчы Боерыгына Тәртипкә китерелгән 16 нчы кушымтасына китерелгән форма буенча, уллыкка (кызлыкка ) алынган баланы билгеләнгән тәртиптә исәпкә кую йөкләмәсен; | |
| | г) уллыкка (кызлыкка) алынган баланың яшәү шартларын Россия Мәгариф министрлыгының 136 нчы Боерыгына Тәртипкә китерелгән 17 нче кушымтадагы  форма буенча тикшерү;<br>д) чит ил гражданинының шәхесен раслаучы һәм Россия Федерациясе тарафыннан шул сыйфатта таныла торган документның күчермәсе;<br>е) үз гражданы булган дәүләтнең компетентлы органы бәяләмәсе (Россия Федерациясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданины яки үзендә булган дәүләт гражданлыгы булмаган зат өчен яшәү урыны, яшәү шартлары һәм уллыкка (кызлыкка) алу мөмкинлеге турында. Йомгаклау өчен аның гаиләсе турында фотоматериаллар бирелә; | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ж) Россия Федерациясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданының, чит ил гражданының яки гражданлыгы булмаган затның яшәү дәүләтенең компетентлы органының шартларын тикшереп тору йөкләмәсе уллыкка (кызлыкка) алынган баланың тормыш һәм тәрбия шартлары турында хисаплар тапшырырга һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Россия Федерациясе территориясендә балаларны уллыкка (кызлыкка) алу буенча чит ил дәүләтләре органнары һәм оешмалары эшчәнлеге турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә, уллыкка (кызлыкка) алучы гаиләсендә баланы уллыкка (кызлыкка) алуның 14 нче кушымтасында китерелгән форма буенча уллыкка (кызлыкка) алучы гаиләсендә балага яшәү һәм тәрбияләү шартлары турында хисаплар тапшырырга һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Россия Федерациясе 2006 елның 4 ноябре 654 карары нигезендә уллыкка (кызлыкка) алучы гаиләсендә баланың яшәү һәм тәрбияләү шартлары турында хисаплар РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 136 номерлы боерыгына Тәртипкә китерелгән 8 нче кушымтада бирелгән формасы буенча бирелә;<br>з) Россия Федерациясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданының компетентлы яшәү органының, чит ил гражданының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 29 мартындагы 275 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 136 номерлы боерыгына 15 нче кушымтада китерелгән форма буенча уллыкка (кызлыкка) алынган баланы Россия Федерациясе консуллык учреждениесендә исәпкә кую кагыйдәләрендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 29 мартындагы 275 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе гражданнары булган һәм чит ил гражданнары яисә гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан уллыкка алынган балаларны исәпкә кую срокларында исәпкә куелуын контрольдә тоту;<br>и) гражданы уллыкка (кызлыкка) алучы кандидат булган дәүләтнең закон чыгаруда бер җенес затлары арасында төзелгән берлекне тану (никахта булмаган зат мөрәҗәгать иткән очракта бирелә) булган дәүләтнең компетентлы органы документы; | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | к)әлеге пунктның «е» - «и» пунктчаларында күрсәтелгән документларны әзерләү буенча компетентлы органның вәкаләтләрен раслый торган чит ил оешмасының лицензиясе (яисә башка документ) күчермәсен;<br>л)  чит ил законнары тарафыннан мондый документларга карата куела торган таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән уллыкка (кызлыкка) алучы кандидатларны әзерләүне узу турында таныклык яки башка документның күчермәсе; | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | м)чит дәүләт законнары тарафыннан мондый документларга карата белдерелә торган таләпләр нигезендә расланган, аның буенча уллыкка (кызлыкка) алучыларга кандидатлар әзерләү үткәрелгән;программаның күчермәсен,<br>н)уллыкка (кызлыкка) кандидатлар әзерләү узу турында документ биргән чит ил оешмасының гражданнарны күрсәтелгән әзерләүне гамәлгә ашыру һәм тиешле документ бирү хокукын раслаучы документ.<br>4. Чит ил гражданы, баланы уллыкка алу вакытына башка дәүләткә бер елдан артык вакытка (эшкә яисә башка сәбәпләр аркасында) чыккан очракта, 3 пунктның «а» - «д», «и» һәм «л»-«н» пунктчаларында күрсәтелгән документлардан тыш, түбәндәге документларны тапшыра:<br>а) уллыкка алучы (кызлыкка алучы) булу мөмкинлеге турында бәяләмә һәм уллыкка (кызлыкка) алынган баланы яшәү һәм тәрбияләү шартларын тикшереп торуны һәм аны Россия Федерациясе консуллык учреждениесендә даими яшәү урыны дәүләткә кайту буенча консуллык учетына куюны йөкләүне, әлеге дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бәяләмәне;<br>б) уллыкка (кызлыкка) алынган баланың яшәү шартларын һәм тәрбияләү шартларын тикшереп тору һәм Россия Федерациясе консуллык учреждениесендә бу дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән уллыкка (кызлыкка) алынган вакытта яши торган дәүләткә килгәч консуллык учетына кую йөкләмәсе;<br>в) әлеге пунктның «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән документларны әзерләү буенча компетентлы органның вәкаләтләрен раслый торган чит ил оешмасының лицензиясе (яисә башка документ) күчермәсен.<br>5. Ул гражданин булмаган дәүләт территориясендә даими яшәүче чит ил гражданы, 3 пунктның «а»-«д», «һәм» пунктчаларында күрсәтелгән документлардан тыш, дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән 3 пунктның «е»-«з» һәм «к»-«н» пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшыра. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 6.Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы уллыкка алырга теләгән, баланың туганы булган чит ил гражданы, 3-5 пунктларында каралган документлардан тыш, опека һәм попечительлек органнарына уллыкка алына торган бала белән туганлыгын раслаучы документлар тапшыра. | | |
| | 3-5 пунктлар нигезендә тапшырыла торган барлык документлар билгеләнгән тәртиптә, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса легальләштерелергә тиеш.<br>Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә, рус теленә тәрҗемә ителгән, һәм тәрҗемә Россия Федерациясенең консуллык учреждениесендә яисә Россия Федерациясенең дипломатик вәкиллегендә чит ил гражданының яшәү урыны дәүләттә йә Россия Федерациясе территориясендә нотариус тарафыннан таныкланырга тиеш.<br>3 пунктның «а»-«г» пунктчаларында күрсәтелгән документлар аларны төзү көненнән ел дәвамында карауга алына, ә 3 пунктның «е»-«к» пунктчаларында күрсәтелгән, 4 пунктның «а»-«в» пунктчаларында күрсәтелгән документлар аларны биргән көннән алып бер ел дәвамында карала.<br>Әгәр чит дәүләт законнарында 3 пунктның «е»-«н» пунктчаларында һәм 4 пунктның «а»-«в» пунктчаларында күрсәтелгән документларның гамәлдә булуының башка срогы каралган булса, алар тиешле дәүләт законнарында билгеләнгән срок дәвамында каралырга мөмкин. | | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документлар исемлеге | Гражданның яшәү урыны буенча бирелгән опека һәм попечительлек органының гражданның уллыкка алучы, опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмәсе | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда аларны килештерү дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителә торган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| | 4 пунктта, алар тиешле дәүләт законнарында билгеләнгән срок дәвамында каралырга мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Гражданның уллыкка (кызлыкка) алу мөмкинлеге, опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында гражданның яшәү урыны буенча бирелгән опека һәм попечительлек органы бәяләмәсе | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда аларны килештерү дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителә торган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Мөрәҗәгать итүчене кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш.<br><br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү срогы | Гариза килеп ирешкән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Әлеге урын: һаваны кондиционерлау системасы; янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы; мәгълүмат стендлары,Татарстан Республикасы телекоммуникацияләренең дәүләт интеграцияләнгән системасына тоташтырылган мәгълүмати киоск; документларны рәсмиләштерү мөмкинлеге булган мебель белән җиһазландырылган булырга тиеш; | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге һәм аның сыйфаты күрсәткечләре | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада кабул ителә торган биналарның урнашуы;<br>2)гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган белгечләрнең, шулай ук биналарның кирәкле санда булуы;<br>3) мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>3) Министрлык вазифаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Мөрәҗәгать итүчегә консультация электрон рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша түбәндәге адрес буенча: http://uslugi.tatar.ru/ һәм Министрлыкның рәсми сайтының Интернет кабул итүе аша: http://www.mon.tatar.ru бирелергә мөмкин. | |

### 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны (гамәлләрне) башкару үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеге тасвирламасы.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үтәүне үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән балалар турында төбәк банкына мөрәҗәгать иткән белешмәләр һәм балалар турында төбәк белешмәләр банкыннан балалар турында белешмәләр алу өчен мөрәҗәгать итүчеләрне исәпкә алу;

3) балалар турында төбәк банкка белешмәләр кертү, мөрәҗәгать итүчегә балалар турында төбәк белешмәләр банкыннан ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында мәгълүмат бирү;

4) баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче мөрәҗәгать итүчеләргә алар тарафыннан сайланган ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балага баруга юлламалар бирү;

5) төбәк банкта балалар турында белешмәләр булмаган очракта, алар теләкләренә туры китереп, гражданнарга ярдәм күрсәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 2 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, электрон почта, Министрлыкның рәсми сайтының интернет-кабул итүе аша (http://www.mon.tatar.ru) һәм (яисә) хат язып Министрлыкка дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация бирү өчен мөрәҗәгать итә.

Министрлык хезмәткәре дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча мөрәҗәгать итүчене консультацияли.

Министрлык хезмәткәре дәүләт хезмәтен күрсәтү предметына мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза бланкын бирә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документлар исемлегенең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация, искәрмәләр.

3.3. Баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүчеләрнең төбәк банктан балалар турында белешмәләр алу өчен мөрәҗәгать итүләре һәм балалар турында мәгълүмат алу өчен төбәк банкка мөрәҗәгать итүчеләр хакында белешмәләрне исәпкә алу.

3.3.1. Административ процедураны гамәлгә ашыра башлау өчен гариза бирүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә әлеге регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документларны Министрлыкка тапшыру нигез булып тора.

3.3.2. Министрлык тәкъдим ителгән документларны асылда карый:

гариза бирүченең шәхесен билгели, шул исәптән шәхесне раслый торган документны тикшерә;

граждан тарафыннан тапшырылган барлык кирәкле документларның әлеге регламентның 2.5. пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен һәм аларның үтәлешен тикшерә.

3.3.3. Әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булган очракта, Министрлык гариза бирүчегә тапшырылган документларны кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп кире кайтара.

Әлеге Регламентның 3.3.3 пунктында билгеләнгән процедуралар гариза һәм документлар алганнан соң 10 эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган документларны карау, гариза бирүчегә документларны, балалар турында мәгълүматларны төбәк банкка кертүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, язма рәвештә кире кайтару.

3.4. Төбәк банкына балалар турында белешмәләр кертү, мөрәҗәгать итүчегә балалар турында төбәк банкыннан ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында мәгълүмат бирү.

3.4.1. Әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, Министрлык әлеге гражданның ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк банктагы мәгълүматтан файдалана алуын тәэмин итү максатларында балалар турында белешмәләрнең төбәк банкына граждан турында белешмәләр кертә.

Гражданны төбәк балалар турында мәгълүматлар банкына керткәннән соң, Министрлык танышу өчен аның теләкләренә туры килгән балалар анкеталарын бирә.

Әлеге Регламентның 3.4 пунктында билгеләнгән процедуралар гариза һәм шушы Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны алган көннән соң 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: балалар турында төбәк белешмәләр банкына граждан турында белешмәләр кертү һәм мөрәҗәгать итүчегә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында мәгълүмат бирү.

3.5. Баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче мөрәҗәгать итүчеләргә алар тарафыннан сайланган ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы карауга юллама бирү.

3.5.1. Гражданның анкета мәгълүматлары белән танышкан балага килергә ризалыгы булган очракта, Министрлык күрсәтелгән гражданга 8 нче кушымтада Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 136 номерлы Боерыгына китерелгән форма буенча әлеге балага бару өчен юллама бирә.

3.5.2. Һәр балага аерым юллама бирелә.

Әгәр граждан үз гаиләсенә тәрбиягә бер баладан артык бала алырга теләк белдергән булса һәм гаризаны абыйлы-энеле (апалы-сеңелле) булган һәм бер оешмада булган берничә балага бирүне сорап, рәсмиләштергән булса, Министрлык күрсәтелгән барлык балаларга баруга бер юллама бирә.

Гражданга карап кайту өчен бер үк вакытта бирелә торган балалар саны гражданның үз гаиләсенә баланы (балаларны) кабул итү теләге турында гаризасында күрсәтелгән балалар санынннан артып китә алмый.

3.5.3. Граждан үзе карап кайткан баланы тәрбиягә алудан баш тартса, аның ризалыгы белән аңа үзе сайлаган башка балага бару өчен юллама бирелә.

3.5.4. Чит ил гражданнары документларын уллыкка алу буенча чит ил оешмасы вәкиллеге хезмәткәре (алга таба - вәкиллек хезмәткәре) тарафыннан чит ил гражданы өчен билгеләнгән тәртиптә сайланган бала турында мәгълүмат тапшырылган очракта, Министрлык тарафыннан 19 нчы кушымтада Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 136 нчы номерлы Боерыгына китерелгән форма буенча чит ил оешмасы вәкиллеге хезмәткәренә хәбәр ителә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүченең баланы карарга ризалыгы чыкканнан соң 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән мөрәҗәгать итүчегә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган үзе сайлаган балага баруга юллама бирү.

3.6. Төбәк банкында балалар турында белешмәләр булмаган очракта, гражданнарга аларның теләкләренә туры килә торган белешмәләр бирүдә ярдәм итү.

3.6.1. Төбәк белешмәләр банкында граждан үз гаиләсенә алырга теләгән ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала турында белешмәләр булмаса, ул мондый баланы алга таба эзләү үтенече белән язма рәвештә гариза бирергә хокуклы.

3.6.2. Министрлык айга кимендә бер тапкыр язма рәвештә (почта элемтәсе, факсимиль элемтә яисә электрон почта аша) төбәк банкка балалар турында

белешмәләрнең яңа анкеталары керүе турында хәбәр итә, алар гражданның теләгенә туры килә торган яисә мондый белешмәләрнең булмавы турында хәбәр итә.

Процедураларның нәтиҗәсе: балалар турында төбәк банкына яңа анкета керүе турында гражданга хәбәр итү.

3.6.3. Әгәр граждан, үз теләкләренә туры килә торган белешмәләре булган балаларның яңа анкеталарының балалары турында мәгълүматлар төбәк банкына керү турында ике тапкыр хәбәр алганнан соң, баланың яңа анкеталары белән танышу өчен килмәсә, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы (балаларны) эзләү туктатыла һәм киләчәктә гражданның язма гаризасы нигезендә, исәпкә алуны туктату өчен нигез булмаганда, аның турында мәгълүмат эзләү яңадан торгызыла.

Процедура нәтиҗәсе: балалар турында төбәк белешмәләр банкында бала эзләүне туктату.

3.6.4. Белешмәләр банкында гражданның теләкләренә туры килә торган балалар турында белешмәләр булмаган очракта, Министрлык балалар турындагы белешмәләрнең төбәк белешмәләр банкында исәптә торган граждан өчен федераль банкта балалар турында белешмәләр бирү турындагы гариза белән Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 136 номерлы боерыгына 23 нче кушымтада китерелгән форма буенча федераль операторга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Процедура нәтиҗәсе: ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында Федераль банкта исәптә торучы балалар турында белешмәләр бирү турында сорау.

3.6.5. Төбәк банкта гариза бирүче турындагы белешмәләрне исәпкә алу түбәндәге очракларда туктатыла:

гражданинның ата-ана каравыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алуы. Әгәр граждан үз гаиләсенә бердән артык бала алырга теләк белдерсә, төбәк мәгълүмат банкында граждан турында мәгълүматларны исәпкә алу гражданның ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар саныннан граждан анкетасында күрсәтелгән һәм граждан үз гаиләсенә опека һәм попечительлек органы (чит дәүләтнең компетентлы органы) бәяләмәсе нигезендә кабул итә ала торган балалар саныннан артмаган очракта туктатыла;

гражданның балалар турында белешмәләр төбәк банкында аның турында белешмәләрне исәпкә алуны туктату турында язма формада гариза бирүе;

гражданга баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алу мөмкинлеге биргән шартларга үзгәрешләр кертү (шул исәптән гражданның яшәү урыны буенча бирелгән опека һәм попечительлек органы бәяләмәсе гамәлдән чыккан очракта, гражданның уллыкка алучы, опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында;

Процедураның нәтиҗәсе: төбәк банкта гариза бирүче турындагы белешмәләрне исәпкә алуны туктату.

3.7. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба - күпфункцияле үзәк) аша дәүләт хезмәте күрсәтү.

3.7.1. Күп функцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтелми.

**4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм формалары**

4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәтен күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карарлар кабул итүне һәм Министрлыкның вазифаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләре булган мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү.

- эш башкаруны алып баруны билгеләнгән тәртиптә тикшерү үткәрелә;

- билгеләнгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә дәүләт хезмәте күрсәтүгә (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча бәйле барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр кылуны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру һәм карарлар кабул итү максатларында министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелегенең үтәлешен агымдагы контрольдә тоту дәүләт хезмәтен күрсәтүне оештыру өчен җаваплы белгеч, эш башкару хезмәте белгечләре тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге министрлыкның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылган очракта, гаепле затлар закон нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4.Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатьләрен вакытында карамау өчен җаваплы.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу аша башкарыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органнарның, шулай ук аларның вазифаи затларының һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү буенча судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларның гамәлләренең (гамәл кылмавының) судка кадәр тәртибендә Татарстан Республикасы Министрлыгына яисә Министрлар Кабинетына шикаять бирү хокукына ия.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасын теркәү срогын бозу;

дәүләт хезмәтен күрсәтү срогын бозу;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документларны таләп итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның һәм дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазифаи затның документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять кәгазь чыганакта яисә электрон формада язма рәвештә бирелә.

Шикаятьне почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mon.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау срогы - аны теркәгән көннән алып 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазифаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга шикаять биргән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең исеме;;

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), гариза бирүченең – физик затның яшәү урыны турында белешмәләр яки атамасы, мөрәҗәгать итүче - юридик зат урнашкан урын турында белешмәләр, шулай ук телефон номеры (номеры), электрон почта адресы (адресы) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Мондый очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять аны тапшырган дәүләт хезмәтен күрсәтүче тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Министрлык түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүе нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән хаталарны, ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүләрне кире кайтару, шулай ук башка формаларда;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге Регламентның 5.7. пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивацияле җавап электрон формада җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яки карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләрен билгеләгән очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләргә бирелгән вазифаи зат шунда ук булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында белешмәләрнең төбәк банкын формалаштыру, алып бару һәм алардан файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта**

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы һәм аны тәкъдим итүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазифаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге**

| Фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Мосабирова Зөлфия Вазыйх кызы-бүлек башлыгы | (8-843) 294-95-66 | Zulfiya.Musabirova@tatar.ru |

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында белешмәләрнең төбәк банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта**

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында белешмәләрнең төбәк банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең

БЛОК-СХЕМАСЫ


Шартлы билгеләр:



Дәүләт хезмәте күрсәтүнең башлануы яисә тәмамлануы



Сайлап алу, карар кабул итү ситуациясе



Операция, гамәл, чара

Дәүләт хезмәтен күрсәтү БЛОК-СХЕМАсы

